**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«25» 01 2021 ел Яр Чаллы № 131

«2021-2023 елларга Тукай муниципаль районында ирекле ярдәмчелекне (волонтерлыкны) үстерү һәм аңа ярдәм итү» ведомствоара программасын раслау турында

Тукай муниципаль районында, җирле милли, социаль-икътисадый, экологик, мәдәни һәм башка үзенчәлекләрне исәпкә алып, массакүләм оештырылган ирекле ярдәмчеләр хәрәкәтен үстерү максатында, Россия Федерациясе Президентының 2009 елның 16 январендагы ПР-38 номерлы күрсәтмәләре исемлеген үтәү йөзеннән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 27 декабрендәге 2950-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган «2025 елга кадәр Россия Федерациясендә ирекле ярдәмчелекне (волонтерлыкны) үстерү концепциясе» нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. «2021-2023 елларга Тукай муниипаль районында ирекле ярдәмчелекне (волонтерлыкны) үстерү һәм аңа ярдәм итү» район программасын кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары И.Ш. Бариевка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 25 01. 131 номерлы карарына кушымта

**«2021-2023 елларга Тукай муниципаль районында ирекле ярдәмчелекне (волонтерлыкны) үстерү һәм аңа ярдәм итү» ведомствоара программасы**

**Яр Чаллы шәһәре**
**2021 ел**

ЭЧТӘЛЕГЕ


1. Программа паспорты

2. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа ысулы белән хәл итү кирәклеген нигезләү

3.

4. Программаның, тормышка ашыру срокларын күрсәтеп, төп максатлары

5. Программа чаралары системасы

6. Программаны тормышка ашыру механизмы һәм көтелгән нәтиҗәләр

7. Ирекле ярдәмчелек эшчәнлегенең төп формалары һәм юнәлешләре

8. Программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген билгеләргә мөмкинлек бирүче индикаторлар

9. Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү

10. Программаны тормышка ашыру буенча чаралар


**Программа паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2021-2023 елларга Тукай муниципаль районында ирекле ярдәмчелеккә (волонтерлыкка) ярдәм итү һәм аны үстерү» муниципаль программасы (алга таба - Программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез (хокукый акт исеме, датасы һәм номеры) | «Ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 30 июнендәге 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы;<br>«Татарстан Республикасында яшьләр һәм дәүләт яшьләр сәясәте турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы законы;<br>2025 елга кадәр Россия Федерациясе субъекты территориясендә ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) үсешенә ярдәм итү концепциясен гамәлгә ашыру буенча чаралар планы (20.06.2009 ел, № 5486п-П44);<br>«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>«Хәйрия эшчәнлеге һәм ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) турында» 1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номерлы Федераль закон. |
| Программаны төп эшләүчеләр | Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| Программаны башкаручылар | 1. Программаны башкаручылар булып тора:<br>-Башкарма комтетның яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге;<br>- «Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ;<br>- Башкарма комитетның мәдәният бүлеге;<br>- Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Тукай муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге (килешү буенча);<br>- «Якты юл» («Светлый путь») район газетасы (килешү буенча);<br>- Үзәк район хастаханәсе ДАССУ (килешү буенча);<br>- Башкарма комитетның төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге;<br>- учреждениеләр, оешмалар, фондлар, иҗтимагый берләшмәләр (килешү буенча).<br>2. Программаның координаторы булып Башкарма комитетның яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге тора<br>3. Хезмәттәшлек тәртибе:<br>программаны үтәүчеләр программада каралган чараларны район программалары, үз оештыру планнары нигезендә мөстәкыйль рәвештә тормышка ашыралар, шулай ук Тукай районында ирекле ярдәмчеләр (волонтерлар) хәрәкәтен үстерүгә юнәлдерелгән уртак чаралар, акцияләр оештыра һәм үткәрә алалар;<br>программаны башкаручы, алдан килешенеп, үз чараларын үткәрүгә башка башкаручыларны, шулай ук кызыксынган катнашучыларны җәлеп итә ала;<br>программаны башкаручылар, максатчан аудиторияне күбрәк җәлеп итү максатыннан, хокукый тематика буенча агарту характерындагы мәгълүмати материаллар белән, аларны рәсми сайтларда урнаштыру һәм башка ысуллар белән тарату өчен, үзара алмаша алалар.<br>4. Программа чаралары башкаручылар тарафыннан үз компетенцияләре кысаларында:<br>район программалары чаралары; |

| | |
|---|---|
| | бюджеттан тыш чаралар;<br>башка төр финанслау хисабына гамәлгә ашырыла.<br>5. Программа чараларын нәтиҗәле гамәлгә ашыру максатында, башкаручыларга (ярдәмче башкаручыларга) координатор (җаваплы зат) запросы буенча, күрсәтелгән запрос алынганнан соң 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, Программа координаторына (җаваплы затка) аларны оештыру һәм үткәрү турында мәгълүмат бирергә кирәк. |
| Программаның максаты | Тукай муниципаль районында, җирле милли, социаль-икътисадый, экологик, мәдәни һәм башка үзенчәлекләрне исәпкә алып, массакүләм оештырылган ирекле ярдәмчеләр хәрәкәтен үстерү |
| Программаның бурычлары | - районда ирекле ярдәмчелек эшчәнлеге үсешенә мониторинг оештыру;<br>- ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлегенең аерым юнәлешләрен үстерү;<br>- ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлегенә ярдәм итү механизмнарын үстерү;<br>- ведомствоара хезмәттәшлек һәм ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) берләшмәләре эшчәнлеген координацияләү системасын булдыру;<br>- район халкы арасында ирекле ярдәмчеләр (волонтерлар) хәрәкәтенең уңай имиджын булдыру |
| Программаны тормышка ашыру вакыты һәм этаплары | 2021-2023 еллар |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре | 2023 елга чараларны тормышка ашыру хисабына планлаштырыла:<br>1. Эшчәнлекнең төрле юнәлешләре буенча ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) берләшмәләренең бердәм яңартылган реестрын булдыру, реестрга Тукай муниципаль районында үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) берләшмәләрен 100% кертү.<br>2. Мәгариф учреждениеләре базасында кимендә 300 ирекле ярдәмчене (волонтерны), яшьләр сәясәте учреждениеләре базасында кимендә 100 ирекле ярдәмчене (волонтерны), социаль яклау учреждениеләре базасында кимендә 50 ирекле ярдәмчене (волонтерны), мәдәният учреждениеләре базасында кимендә 50 ирекле ярдәмчене (волонтерны), сәламәтлек саклау учреждениеләре базасында кимендә 40 ирекле ярдәмчене (волонтерны), физик культура һәм спорт учреждениеләре базасында кимендә 70 ирекле ярдәмчене (волонтерны) җәлеп итеп ирекле ярдәмчеләр (волонтерлар) берләшмәләрен төзү һәм аларның эшләп торуы.<br>3. Ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) хәрәкәтен үстерү мәсьәләләрендә, тиешле профильле юнәлешләрдә ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) берләшмәләре эшен координацияләү һәм ярдәм итү өчен профильле ведомстволарга җаваплылык беркетеп, ведомствоара хезмәттәшлек мәйданчыгын булдыру һәм аның эшләп торуы.<br>4. Эшчәнлекнең төрле юнәлешләре буенча ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) берләшмәләре санының 5%ка артуы, шул исәптән ирекле ярдәмчелек эшчәнлеге белән шөгыльләнүче гражданнар санының 10%ка артуы һәм ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) берләшмәләре эшчәнлегенә (чараларына) җәлеп ителгән район халкы санының 10%ка артуы. |

| | |
|---|---|
| Программаны тормышка ашыруны контрольдә тотуны оештыру системасы | Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге программа үтәлешен гомуми контрольдә тота |

## 2 бүлек. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа ысулы белән хәл итү кирәклеген нигезләү

Соңгы унъеллыкта ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) бөтен дөньяда киң таралды. Волонтерлык үсешенә һәм таралуына ярдәм итү социаль һәм яшьләр сәясәтенең өстенлекле юнәлешләренә кертелгән.

Хәзерге дөньяда ирекле ярдәмчелекнең (волонтерлыкның) мөһимлеген билгеләп, аның профилактик әһәмиятен ассызыкларга кирәк. Бүгенге көндә яшьләр арасында тискәре социаль процессларның (девиацияләр, социаль бүленеш һәм тиңдәшлек кризисы, төгәл гражданлык позициясенең булмавы) үсүе күзәтелә, мондый шартларда дәүләт, аерым алганда, муниципалитет, патриотик рухлы, аек фикерле һәм актив яшьләргә мохтаҗ. Ирекле ярдәмчелек (волонтерлык), җәмгыятьнең социаль проблемаларын хәл итүдән тыш, яшьләрне социализацияләүгә һәм мобилизацияләүгә, аларның гражданлык позициясен формалаштыруга юнәлдерелгән.

Ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлеге шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелек, риясызлык кебек әхлакый кыйммәтләрне үстерергә мөмкинлек бирә. Ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) белән шөгыльләнүче гражданнар чаралар һәм акцияләр оештыру, халыкның төрле категорияләре белән аралашу күнекмәләренә өйрәнә, бу аларга хезмәт базарында көндәшлеккә сәләтле булу мөмкинлеге бирә.

Хәзерге вакытта Тукай муниципаль районында 38 ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) берләшмәсе бар, болар: тимурчылар отрядлары, клуб, мәктәп хезмәткәрләре һ. б. Ел саен районда халыкның социаль яктан якланмаган катламнарына ярдәм итүгә, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга, экологик культура формалаштыруга юнәлтелгән 100дән артык чара үткәрелә.

Тукай муниципаль районында бер генә зур чара да ирекле ярдәмчеләрне җәлеп итмичә үткәрелми.

Әмма районда ирекле ярдәмчелек хәрәкәтен үстерү үзәге булмау, ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлеген үстерү һәм аларга ярдәм итү мәсьәләләрендә ирекле ярдәмчеләр отрядларының үзара хезмәттәшлеге аз булу сәбәпле, бөтен эш күләмен исәпкә алып булмый. Нәтиҗәдә, ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлегенә системалы ярдәм күрсәтү механизмнары җитәрлек дәрәҗәдә үсмәгән, муниципаль дәрәҗәдә ирекле ярдәмчеләргә (волонтерларга) грант ярдәме тулысынча юк, ирекле ярдәмче кадрларны әзерләү, яңадан әзерләү һәм квалификацияләрен күтәрүнең, мәгълүмат, методик материаллар алмашуның үзәкләштерелгән системасы юк.

Ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлеге җәмгыятьнең мәгариф, мәдәният, сәламәтлек саклау, әйләнә-тирә мохитне саклау һ.б. өлкәләрендә социаль үсешенең мөһим факторы булуга бәйле рәвештә, Тукай муниципаль районында ирекле ярдәмчелек өлкәсендә муниципаль ярдәм системасын булдырырга һәм ведомствоара хезмәттәшлек масштабларын киңәйтү өчен шартлар булдырырга кирәк.

## 3 бүлек Программаның, тормышка ашыру срокларын күрсәтеп, төп максатлары

Программаны тормышка ашыру өч елга – 2021-2023 елларга исәпләнгән.

Программаның максаты - Тукай муниципаль районында, җирле милли, социаль-икътисадый, экологик, мәдәни һәм башка үзенчәлекләрне исәпкә алып, массакүләм оештырылган ирекле ярдәмчеләр хәрәкәтен үстерү.

Программаның бурычлары:

- районда ирекле ярдәмчелек эшчәнлеге үсешенә мониторинг оештыру;
- ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлегенең аерым юнәлешләрен үстерү;
- ведомствоара хезмәттәшлек һәм ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) берләшмәләре эшчәнлеген координацияләү системасын булдыру;

- ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлегенә ярдәм итү механизмнарын үстерү;

- район халкы арасында ирекле ярдәмчеләр (волонтерлар) хәрәкәтенең уңай имиджын булдыру.

## 4 бүлек. Программа чаралары системасы

Программа чаралары Тукай районында ирекле ярдәмчелекне (волонтерлыкны) үстерү өлкәсендә ведомствоара хезмәттәшлек принципларына нигезләнеп билгеләнгән, ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) өлкәсендә норматив-хокукый документлар белән регламентланган.

Программа чараларын тормышка ашыру срогы: 2021-2023 еллар.

Программа чаралары системасы түбәндәге юнәлешләр буенча эшләрне үз эченә ала:

- ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) өлкәсендә законнар һәм башка норматив хокукый актларны муниципаль район дәрәҗәсендә гамәлгә ашыруны тәэмин итү;
- ирекле ярдәмчеләр (волонтерлар) һәм аларның хезмәтен исәпкә алуның бердәм базасын булдыру;
- районның барлык ирекле ярдәмчеләр отрядлары һәм волонтерлары эшчәнлеген координацияләү;
- ирекле ярдәмчеләр (волонтерлар) хәрәкәтендә катнашучыларны кызыксындыру һәм стимуллаштыру, иң яхшы ирекле ярдәмчеләрне (волонтерларны) бүләкләү ысулларын эшләү;
- ирекле ярдәмчеләр эшчәнлегенә оештыру-методик ярдәм күрсәтү;
- халыкның барлык яшь төркемнәренең - балалар, яшьләр, олылар һәм өлкән яшьтәге затларның ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашу мөмкинлекләрен арттыру;
- район халкы арасында ирекле ярдәмчелекнең (волонтерлыкның) уңай имиджын булдыру.

## 5 бүлек. Программаны тормышка ашыру механизмы һәм көтелгән нәтиҗәләр

Программаны тормышка ашыру механизмы түбәндәгеләрне күздә тота:

1) ирекле ярдәмчелекне (волонтерлыкны) үстерү буенча район ведомствоара комиссиясен төзү;

2) ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучы ирекле ярдәмчеләр (волонтерлар) берләшмәләренең реестрын һәм рейтингын алып бару;

3) эшчәнлекнең төрле юнәлешләре буенча яңа ирекле ярдәмчеләр (волонтерлар) берләшмәләре төзү;

4) ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) юнәлешендә чаралар оештыру;

5) волонтерлар отрядлары командирларыннан координацион совет җыюны оештыру;

6) волонтерларны ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) юнәлешендә чаралар оештыру методикасына өйрәтү;

7) ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлеге белән шөгыльләнүче оешмалар арасында партнерлык элемтәләрен җайга салу, ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) өлкәсендә социаль инициативалар буенча тәҗрибә уртаклашу;

8) ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) юнәлешендә яңа проектлар эшләү һәм гамәлгә кертү;

9) ирекле ярдәмчеләрнең (волонтерларның) иң яхшы тәҗрибәләрен, ирекле ярдәмчеләрне (волонтерларны) бүләкләү;

10) Тукай муниципаль районының ирекле ярдәмчеләр (волонтерлар) хәрәкәте торышы турында еллык аналитик отчет формалаштыру.

Ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) өлкәсендә эшчәнлекнең төрле юнәлешләрендәге ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) берләшмәләре эшчәнлеген Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге координацияләячәк.

Программа чараларын гамәлгә ашыру өчен башкаручылар, эшләрнең составы һәм эзлеклелеге, башкару сроклары һәм җаваплы затлар, шулай ук эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген бәяләү буенча контроль чаралар билгеләнгән (әлеге Программага 1 нче кушымта).

**6 бүлек. Ирекле ярдәмчелек эшчәнлегенең төп формалары һәм юнәлешләре**

Ирекле ярдәмчелек эшчәнлеге шәхси ирекле ярдәмчелек эшчәнлеге, теркәлмәгән берләшмә яки төркем составында ирекле ярдәмчелек эшчәнлеге, ирекле ярдәмчелек оешмасы аша ирекле ярдәмчелек эшчәнлеге формасында башкарыла ала.

Программа ирекле ярдәмчелекнең (волонтерлыкның) төп юнәлешләре аша тормышка ашырыла: мәдәни, социаль, вакыйга, экологик, гаилә, корпоратив ирекле ярдәмчелек (волонтерлык), «көмеш яшь» волонтерлары, Җиңү волонтерлары, волонтерлар-медиклар, медиаволонтерлар, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өлкәсендә ирекле ярдәмчелек (волонтерлык), җәмәгать куркынычсызлыгы өлкәсендә ирекле ярдәмчелек (волонтерлык), яшәү урыны буенча ирекле ярдәмчелек (волонтерлык), инклюзив ирекле ярдәмчелек (волонтерлык), спорт волонтерлыгы.

Мәгарифтә ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлеге мәгърифәтчелек һәм консультатив эшчәнлек, остазлык, тьюторлык аша, аларның һөнәри компетенцияләрен кулланып, укытучыларның һәм укучыларның ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) проектларында һәм белем бирүнең барлык дәрәҗәләрендәге мәгариф оешмалары программаларында катнашуын, мәгариф оешмаларының, социаль юнәлешле коммерциясез оешмаларның уртак хәйрия программаларын тормышка ашыруны күздә тотып, «ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) аша уку» форматында тормышка ашырыла ала. Мәгариф өлкәсендә гражданлык-патриотик тәрбия бирүдә ирекле ярдәмчелекне (волонтерлыкны) үстерү күздә тотыла, түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1. Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарына ярдәм күрсәтү, ветераннар оешмалары белән үзара хезмәттәшлек;
2. Ватанны саклаганда һәлак булганнарның истәлеген мәңгеләштерүгә ярдәм итү;
3. Россия тарихындагы истәлекле вакыйгаларга багышланган акцияләрне оештыруда ирекле ярдәмчеләрнең (волонтерларның) катнашуы.

Сәламәтлек саклау өлкәсендә ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлеген гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре булып тора:

1. гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүдә ярдәм;
2. халыкның сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруда, авырулар барлыкка килүне һәм таралуны профилактикалауда ярдәм итү;
3. медицина оешмаларының пациентларына аларның урнашу урыны буенча мәгълүмати, консультатив, агарту, ял итү һәм башка ярдәм күрсәтү;
4. дәвалау һәм реабилитация учреждениеләрендә пациентларны карауда ярдәм.

Халыкка социаль ярдәм һәм социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) социаль ярдәмгә һәм социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ булган гражданнарга түләүсез ярдәм күрсәтүдә ирекле ярдәмчеләрнең (волонтерларның) катнашуын, шул исәптән түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1. социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында (картлар һәм инвалидлар өчен интернат-йортларда (пансионатларда), психоневрологик интернатларда, шул исәптән балалар, социаль хезмәт күрсәтү үзәкләрендә, социаль адаптация үзәкләрендә һ.б.) ярдәм күрсәтү;
2. өйдә социаль хезмәтләр күрсәтүдә ярдәм итү;
3. мохтаҗларга социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыруда ярдәм итү;
4. авыр тормыш хәлендә калган затларга ярдәм күрсәтү, шулай ук социаль ятимлекне профилактикалауны тәэмин итү;
5. ятим балалар, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр, наркотикларга һәм алкогольгә бәйле кешеләр, инвалидлар, иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны һәм башка мохтаҗ

категорияләрне социальләштерү программаларын гамәлгә ашыруда булышлык күрсәтү.

Мәдәният өлкәсендә ирекле ярдәмчелекнең (волонтерлыкның) төп юнәлешләре булып тора:

1. мәдәният оешмалары эшчәнлегенә ярдәм итү;
2. мәдәният өлкәсендә массакүләм чаралар оештыру һәм үткәрүдә ярдәм итү;
3. мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне) саклау буенча эшләрне тормышка ашыруда катнашу;
4. мәдәният һәм сәнгать эшлекләләрен ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлегенә җәлеп итү.

Физик культура һәм спорт өлкәсендә ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) үсешенең төп юнәлешләре булып тора:

1. физкультура һәм спорт чараларын оештыру һәм (яки) үткәрүдә катнашу;
2. спорт объектларын оештыруда һәм аларның эшчәнлегендә катнашу;
3. сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм инвалидлар арасында спорт чараларын оештыру һәм үткәрүдә катнашу;
4. сәламәт яшәү рәвешен, физик культураны һәм спортны пропагандалауда катнашу;
5. танылган спортчыларны, физик культура һәм спорт өлкәсендә профессиональ хезмәткәрләрне ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлегенә җәлеп итү.

Табигатьне саклау өлкәсендә ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлеген үстерүнең төп юнәлешләре булып тора:

1. табигый экосистемаларны торгызуга, табигый тирәлекне чүп-чардан чистартуга, шул исәптән калдыкларны аерым җыюны оештыруга ярдәм итү;
2. табигатьне саклау эшчәнлегенә ярдәм итү;
3. экологик культура һәм экологик агарту формалаштыруга ярдәм итү;
4. хайваннар дөньясын саклауда, аларның яшәү тирәлеген саклауда һәм торгызуда катнашу;
5. табигый комплексларны табигый халәттә саклау өлкәсендә аеруча саклана торган табигый территорияләр белән идарә итүне гамәлгә ашыручы оешмаларга ярдәм күрсәтү һәм Россия Федерациясенең урман законнарын бозу фактларын ачыклау эшендә ярдәм итү.

Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өлкәсендә ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) үсешенең төп юнәлешләренә керә:

1. гадәттән тыш хәлләрне һәм янгыннарны кисәтү, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклауның төп ысулларына өйрәтүгә юнәлдерелгән профилактик чараларны ирекле ярдәмчеләр (волонтерлар) катнашында популярлаштыру һәм үзләштерү;
2. техноген һәм табигый характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерүдә ирекле ярдәмчеләрнең (волонтерларның) катнашуы;
3. профессиональ коткаручылар һәм янгын сагы хезмәткәрләренең коткаручыларны-ирекле ярдәмчеләрне һәм ирекле янгын сүндерүчеләрне укытуда катнашуын күздә тоткан остазлыкны үстерү.

Югалган кешеләрне эзләүдә ярдәм итү, шулай ук эчке эшләр органнарына һәм башка хокук саклау органнарына ирекле халык дружиналарында җәмәгать тәртибен саклауда булышлык күрсәтү ирекле ярдәмчелекнең (волонтерлыкның) мөһим өлкәсе булып тора.

Территорияне төзекләндерү һәм яшелләндерү, балаларның һәм яшүсмерләрнең ялын оештыру, өлкәннәргә ярдәм итү максатыннан, яшәү урыны буенча ирекле ярдәмчелекне (волонтерлыкны) оештыру территориаль иҗтимагый үзидарәне үстерүнең мөһим ресурсы булып тора.

Инклюзив ирекле ярдәмчелек (волонтерлык), өлкән яшьтәге гражданнар ирекле ярдәмчелеге (волонтерлыгы), гаилә формасында тормышка ашырыла торган ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) һәм корпоратив ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) була.

Инклюзив ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрне ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлегенә кетүне һәм пенсия, пенсия алды яшендәге кешеләрне ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлегенә җәлеп итүне күздә тота, бу җәмгыяттә өлкән буынга ихтыяҗны арттыра, буыннар арсындагы элемтәләрне ныгыта һәм гореф-гадәтләрне саклауга ярдәм итә.

## 7 бүлек. Программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген билгеләргә мөмкинлек бирүче индикаторлар

| № | Индикатор исеме | Исәпләү формуласы | Финанслау |
|---|---|---|---|
| 1. | Эшчәнлекнең төрле юнәлешләре буенча ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) берләшмәләренең бердәм яңартылган реестрын булдыру, Тукай районының ирекле ярдәмчеләр (волонтерлар) хәрәкәтенең торышы турында еллык аналитик хисап бирү. Тукай районында үз эшчәнлеген алып баручы ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) берләшмәләрен реестрга 100% кертү | Реестр булуы. Реестрдагы мәгълүматны елына кимендә 4 тапкыр яңарту. Реестрда күрсәтелгән: ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) берләшмәсенең, аның җитәкчесенең исеме, ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) берләшмәсенең контакт мәгълүматлары | Тукай районы ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) хәрәкәтенең торышы турында аналитик хисап Бердәм реестр мәгълүматлары буенча |
| 2. | Мәгариф учреждениеләре базасында кимендә 300 ирекле ярдәмчене (волонтерны), яшьләр сәясәте учреждениеләре базасында кимендә 100 ирекле ярдәмчене (волонтерны), социаль яклау учреждениеләре базасында кимендә 50 ирекле ярдәмчене (волонтерны), мәдәният учреждениеләре базасында кимендә 50 ирекле ярдәмчене (волонтерны), сәламәтлек саклау учреждениеләре базасында кимендә 40 ирекле ярдәмчене (волонтерны), физик культура һәм спорт учреждениеләре базасында кимендә 70 ирекле ярдәмчене (волонтерны) җәлеп итеп ирекле ярдәмчеләр (волонтерлар) берләшмәләрен төзү һәм аларның эшләп торуы | Ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) берләшмәләре саны, берләшмәләр составына керүче ирекле ярдәмчеләр (волонтерлар) саны | Ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) берләшмәләре эшчәнлеге юнәлеше буенча ведомстволарның (бүлекләрнең) хисаплары |
| 3. | Ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) хәрәкәтен үстерү мәсьәләләрендә, тиешле профильле юнәлешләрдә ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) берләшмәләре эшен координацияләү һәм ярдәм итү өчен профильле ведомстволарга җаваплылык беркетеп, ведомствоара хезмәттәшлек | Ведомствоара комиссия утырышлары саны елына кимендә 2 тапкыр. Комиссия утырышларында тиешле профильле юнәлешләрдә ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшен координацияләү һәм аларга ярдәм итү өчен җаваплылык беркетелгән | Ведомстволарның (бүлекләрнең) тиешле профильле юнәлешләрдә ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшен координацияләү һәм аларга ярдәм итү турында хисаплары. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | мәйданчыгын булдыру һәм аның эшләп торуы | барлык профильле ведомстволар вәкилләре катнашуы | |
| 4. | Эшчәнлекнең төрле юнәлешләре буенча ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) берләшмәләре санының 5% ка артуы, шул исәптән ирекле ярдәмчелек эшчәнлеге белән шөгыльләнүче гражданнар санының 10% ка артуы һәм ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) берләшмәләре эшчәнлегенә (чараларына) җәлеп ителгән район халкы санының 10% ка артуы | $J_1 = \frac{(D_{пред.} - D) * 100\%}{D_{пред.}}$<br>J1 - ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) берләшмәләре саны арту.<br>$D_{пред.}$ – хисап елы алдыннан килгән елда ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) берләшмәләре саны.<br>D – хисап елында ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) берләшмәләре саны.<br>$J_2 = \frac{(F_{пред.} - F) * 100\%}{F_{пред.}}$<br>$J_2$- ирекле (волонтерлык) берләшмәләре әгъзалары саны арту.<br>$F_{пред.}$– хисап елы алдыннан килгән елда ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) берләшмәләре саны.<br>F – хисап елында ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) берләшмәләре әгъзалары саны.<br>$J_3 = \frac{(C_{пред.} - C) * 100\%}{C_{пред.}}$<br>$J_3$– ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) берләшмәләре эшчәнлегенә (чараларына) җәлеп ителгән район халкы саны арту.<br>$F_{пред.}$ – хисап елына кадәр килгән елда ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) берләшмәләре эшчәнлегенә (чараларына) җәлеп ителгән район халкы саны.<br>F – хисап елында ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) берләшмәләре эшчәнлегенә (чараларына) җәлеп ителгән район халкы саны | Ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) берләшмәләренең хисаплары |
| 5. | Гамәлгә ашырыла торган ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) проектлары, чаралары саны.<br>Программаны гамәлгә ашыру вакыты дәвамында планлаштырылган күрсәткеч - алдагы ел белән чагыштырганда кимендә 5%ка арту. | $J = \frac{(J2-J1)x100\%}{J1}$<br>биредә J1 – узган ел дәвамында гамәлгә ашырылган ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) проектлары саны.<br>J2 - хисап (агымдагы) | Ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) чаралары турында бүлекләрнең аналитик хисаплары |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | J ≥5% | елында гамәлгә ашырыла торган ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) проектлары саны | |

## 8 бүлек. Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә:

- Тукай муниципаль районында ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) хәрәкәтен үстерү өлкәсендә ведомствоара хезмәттәшлек киңәйтеләчәк;
- Тукай муниципаль районы территориясендә яшьләрнең гамәлдәге волонтерлык инициативаларына ярдәм күрсәтеләчәк;
- волонтерлык эшчәнлеге мөмкинлекләре турында гражданнарның мәгълүматы артачак;
- ирекле ярдәмчелек хәрәкәтенә җәлеп ителгән яшьләр саны артачак;
- гамәлгә ашырыла торган ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) проектлары саны артачак;
- эшчәнлек төрләре буенча волонтерлар әзерләү дәрәҗәсе һәм алар үткәрә торган чараларның сыйфаты артачак.

«2021-2023 елларга Тукай
муниципаль районында ирекле
ярдәмчелеккә (волонтерлыкка) ярдәм
итү һәм аны үстерү»
муниципаль программасына
1 нче кушымта

Программа чаралары

| № | Программа чараларының исеме | Программа чараларын башкаручылар | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|
| 1. Ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) өлкәсендә законнар һәм башка норматив хокукый актларны муниципаль район дәрәҗәсендә гамәлгә ашыруны тәэмин итү | | | |
| 1.1 | Ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) оешмалары эшчәнлеген муниципаль дәрәҗәдә контрольдә тотучы һәм координацияләүче дәүләт хакимияте органы - ирекле ярдәмчелекне (волонтерлыкны) үстерү буенча район ведомствоара комиссиясен төзү | Башкарма комтетның яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге<br><br>«Мәгариф идарәсе» МКУ<br><br>Башкарма комитетның мәдәният бүлеге<br><br>«Тукай районы үзәк хастаханәсе» ДАССУ<br><br>ТР Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Тукай районындагы социаль яклау идарәсе<br><br>Төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге | Ирекле ярдәмчелекне (волонтерлыкны) үстерү буенча район ведомствоара комиссиясе утырышларын оештыру (ярты елга кимендә 1 тапкыр), башкарылган эшләр турында хисап әзерләү, проблемалы мәсьәләләр буенча фикер алышу, учреждениеләр эшчәнлегенә анализ ясау һәм шәһәрдә ирекле ярдәмчелек эшчәнлеген үстерүнең нәтиҗәлелеген арттыру буенча тәкъдимнәр эшләү |
| 1.2 | Ирекле ярдәмчеләр (волонтерлар) отрядлары лидерларының координацион | Башкарма комтетның яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Волонтерлар отрядлары арасында мәгълүмат, тәҗрибә алмашу, муниципаль дәрәҗәдә республика һәм бөтенроссия чараларын оештыру |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | советын оештыру | | |
| 2. Ирекле ярдәмчеләр (волонтерлар) һәм аларның хезмәтен исәпкә алуның бердәм базасын булдыру | | | |
| 2.1 | Район волонтерларының бердәм реестрын булдыру | Башкарма комтетның яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Статистика һәм хисап документларын тутыру |
| 3. Район халкының ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашу мөмкинлекләрен арттыру | | | |
| 3.1 | Районның төрле ведомстволары һәм учреждениеләре базасында яңа отрядлар төзү һәм ирекле ярдәмчеләр (волонтерлар) хәрәкәтенең барлык юнәлешләрен үстерү | Башкарма комтетның яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге<br><br>«Мәгариф идарәсе» МКУ<br><br>Башкарма комитетның мәдәният бүлеге<br><br>«Тукай районы үзәк хастаханәсе» ДАССУ<br><br>ТР Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Тукай районындагы социаль яклау идарәсе<br><br>төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге; | Төрле идарә һәм ведомстволар базасында ирекле ярдәмчелек хәрәкәтенең барлык юнәлешләре буенча яңа отрядлар булдыру:<br>- Мәгариф идарәсе - мәгариф өлкәсендә, гражданлык-патриотик тәрбия бирү өлкәсендә ирекле ярдәмчеләр отрядлары, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән ирекле ярдәмчеләр отрядлары (инклюзив ирекле ярдәмчелек), табигатьне саклау һәм экологик агарту өлкәсендә ирекле ярдәмчелек (волонтерлык), медиаволонтерлык;<br>- Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге - спорт өлкәсендә ирекле ярдәмчеләр, вакыйгалар волонтерлыгы (зур, әһәмиятле вакыйгалар һәм чаралар);<br>- Мәдәният идарәсе - мәдәният өлкәсендә ирекле ярдәмчелек;<br>- Сәламәтлек саклау идарәсе - сәламәтлек саклау өлкәсендә ирекле ярдәмчелек;<br>- Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәрендәге социаль яклау идарәсе - халыкка социаль ярдәм һәм социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә ирекле ярдәмчелек, өлкән яшьтәге гражданнарның ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлеге (көмеш волонтерлык);<br>- төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге - территорияләрне төзекләндерү өлкәсендә ирекле ярдәмчеләр, экология һәм табигатьне саклау өлкәсендә ирекле ярдәмчеләр |
| 3.2 | Халыкның барлык яшь төркемнәренең - балалар, яшьләр, олылар һәм өлкән | Башкарма комтетның яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Волонтерлык эшчәнлегендә катнашучы барлык яшь төркемендәге кешеләр санын арттыру |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | яшьтәге затларның ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашуын оештыру | «Мәгариф идарәсе» МКУ<br><br>Башкарма комитетның мәдәният бүлеге<br><br>«Тукай районы үзәк хастаханәсе» ДАССУ<br><br>ТР Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Тукай районындагы социаль яклау идарәсе<br><br>Төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге | |
| 4. Ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) хәрәкәтендә катнашучыларны кызыксындыру һәм стимуллаштыру, иң яхшы тәҗрибәләрне бүләкләү | | | |
| 4.1 | Иң яхшы ирекле ярдәмчелек практикаларын, отрядларын, ирекле ярдәмчеләрне ачыклауга һәм бүләкләүгә юнәлдерелгән чаралар оештыру:<br>- «Елның ирекле ярдәмчесе» Бөтенроссия конкурсының муниципаль этабы,<br>- ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) берләшмәләре арасында социаль проектларга грант конкурсы,<br>- 5 декабрьдә «Ирекле ярдәмче көне» район чарасы, | Башкарма комтетның яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Ирекле ярдәмчелек эшчәнлегенә мотивация формалаштыру, волонтерлык эшчәнлегенә җәлеп ителгән кешеләр һәм гамәлгә ашырыла торган проектлар санын арттыру |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | - Кара диңгез ярына ирекле ярдәмчеләрнең җәйге сменасына иң яхшы ирекле ярдәмчеләрнең сәфәрен оештыру | | |
| 5. Волонтерлык эшчәнлегенең уңай имиджын булдыру | | | |
| 5.1 | Чараларны массакүләм яктырту өчен район массакүләм мәгълүмат чараларын җәлеп итү | «Якты юл» («Светлый путь») район газетасы | Ирекле эшчәнлеккә мотивация формалаштыру, волонтерлык эшчәнлеге турында мәгълүматлы һәм бу эшкә җәлеп ителгән кешеләр санын арттыру |
| 6. Ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) өлкәсендә эшчәнлекне оештыру-методик тәэмин итү | | | |
| 6.1 | Ирекле ярдәмчеләрнең (волонтерларның) компетенцияләрен һәм үткәрелә торган чараларның сыйфатын күтәрү максатында, белем бирү чараларын оештыру:<br>- Ирекле ярдәмчеләр мәктәбе,<br>- ирекле ярдәмчелек турында ачык дәресләр,<br>- Ирекле ярдәмчелек форумы | Башкарма комтетның яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Ирекле ярдәмчелек буенча чаралар оештыру өчен кирәкле белемнәр алу, ирекле ярдәмчелек чараларын оештырганда яңа формалар һәм ысуллар куллану һәм сыйфатны яхшырту |